Р.З.Хайдарова, Г.М.Ахметзянова,
Л.А. Гиниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ

## Укытучылар өчен методик кулланма



3

«Татармультфильм»

УДК 81.432.3-99(=411.2)я72
ББК 811.512.145(073.5)
Х18

Фәнни редакторы
**Р. З. Хәйдәрова**

*Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всего издания или его части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**Хайдарова, Р. З. и др.**

Х18 Государственный (татарский) язык Республики Татарстан: Татар теле. 3 класс: книга для учителя к учебнику для общеобразовательных организаций начального общего образования (для обучающихся, не владеющих татарским языком)/ Р. З. Хайдарова, Г. М. Ахметзянова, Л. А. Гиниятуллина. — Казан: Татармультфильм, 2024. — 48 с.

ISBN 978-5-906508-49-2

УДК 81.432.3-99(=411.2)я72
ББК 811.512.145(073.5)

ISBN 978-5-906508-49-2
© «Татармультфильм» нәшрияты, 2024

Р. З. Хәйдәрова, Г. М. Әхмәтҗанова,
Л. Ә. Гыйниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ

## 3 нче сыйныф

**Укытучылар өчен методик кулланма**

*Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан тәкъдим ителгән*

Казан
2024

## 3 нче сыйныфта «Татар теле» укыту-методик комплекты белән эшләү үзенчәлекләре

Федераль дәүләт башлангыч белем бирү стандартында күрсәтелгәнчә, төп белем бирүнең башлангыч этабы гомуми белем бирүнең нигезе һәм, балаларда белем һәм күнекмәләр булдыру белән беррәттән, аларның уку эшчәнлеген формалаштыруга да нигез сала, гомуми уку күнекмәләрен үстерүне төп максатлар рәтенә куя. Татар теле, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә хезмәт итә.

**Укыту-методик комплекты** (УМК) аша татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү түбәндәге **максатларны** күзаллый:

— башлангыч мәктәп укучысының аралашу даирәсен, аралашу ситуацияләрен исәпкә алып, сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу) буенча укучыларда **коммуникатив компетенция (аралашу осталыгы)** формалаштыру;

— укучының танып белү мөмкинлекләрен, гомуми уку күнекмәләрен, сөйләм культурасын үстерү;

— укучыларның күпмилләтле җирлектә аралашу культурасын формалаштыру, татар халкының мәдәниятенә, милли үзенчәлекләренә карата хөрмәт хисе, мәдәниара диалогка осталык кебек универсаль шәхси күнекмәләр формалаштыру;

— укучыларны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү;

— укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерү.

3 нче сыйныфта укучы рус телле балаларга тәкъдим ителгән укыту-методик комплекты түбәндәге компонентлардан тора:

1. Дәреслек.
2. Дәреслекнең электрон формасы.
3. Укытучы өчен методик ярдәмлек:
   — ишетеп аңлау күнегүләре;
   — федераль эш программасы нигезендә төзелгән календарь-тематик план;
   — контроль-үлчәм материаллары.

УМКга эчтәлек сайлау Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 18.05.2023 елгы 372 нче санлы «Башлангыч гомуми белем бирүнең федераль белем бирү программасын раслау турында»гы хатына (теркәлү вакыты: 12.07.2023 ел, №74229) һәм тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына нигезләнде**.**

Дәреслеккә түбәндәге аралашу темалары кертелде: «Мәктәптә», «Минем көндәлек режимым», «Ашханәдә», «Без әти-әниләргә булышабыз» («Минем гаиләм», «Әти-әниләрнең һөнәрләре», «Мин — өйдә булышчы»), «Туган көн — күңелле бәйрәм», «Яраткан уеннарым», «Шәһәрдә һәм авылда» («Россия һәм Татарстан шәһәрләре», «Безнең урам, өй фатир», «Татарстанда яшәүче милләтләр»), «Милли бәйрәмнәр», «Кечкенә дусларыбыз».

Дәреслектә түбәндәге грамматик материал урын алды:

— исемнәрнең I, II, III зат берлек санда тартым белән төрләнеше;

— *-чы/-че* аффиксалары белән исемнәр ясалышы;

— *-лы/-ле; -сыз/-сез* аффиксалары белән сыйфатлар ясалышы;

— сыйфатларның чагыштыру дәрәҗәсе;

— микъдар һәм тәртип саннары (100–1000);

— *бүген, иртәгә, кичә* вакыт рәвешләре;

— билгеле үткән заман хикәя фигыльнең I, II, III зат берлек һәм күплек саннарда барлык һәм юклык формалары;

— *янында, алдында, артында* бәйлек сүзләренең исемнәр белән кулланылышы;

— «исем+тартымлы исем» төзелмәсе: Казан шәһәре, киемнәр кибете;

— җыйнак һәм җәенке гади җөмләләр;

— гади җөмләләрдә сүз тәртибе.

Методик ярдәмлектә **аудирование** (ишетеп аңлау күнегүләре*)*, укучыларның белемен **контрольгә** алу өчен биремнәр тәкъдим ителә. Ишетеп аңлау күнегүләре һәр дәрестә, дәреснең төрле этапларында кулланыла ала. Ишетеп аңлау күнегүләренә таләпләр кечерәк сыйныфлар өчен чыгарылган ярдәмлекләрдә киң яктыртылу сәбәпле, күнегүләрнең үзләрен бирү белән генә чикләндек.

Укыту процессының уңышлылыгына тәэсир итә торган әһәмиятле факторларның берсе — ул укучыларның белемен **контрольгә** алу. Билгеле булганча, **контроль —** укыту барышын көйли, ягъни, контрольгә карап, укытучы үз эшчәнлеген оештыра. Методика фәне билгеләгәнчә, укучыларның аерым сүзләрне, җөмләләрне тәрҗемә итә белүләре, яисә грамматик категорияләрне аңлый алулары гына **контроль объекты** була алмый. Контрольнең төп объекты — укучының өйрәнелгән лексиканы һәм грамматиканы кулланып, **мөстәкыйль аралаша алуы**.

Тәкъдим ителгән тематик план программа материалның ел дәвамында дәресләргә бүленешен күрсәтә. Календарь-тематик планның коммуникатив максат графасында күрсәтелгән предмет нәтиҗәләре балаларның белем дәрәҗәсенең, ягъни татарча сөйләшеп аралаша алуының күрсәткече булып

тора, шуңа күрә дәрес планын, дәреснең структур этапларын планлаштырганда, аңа игътибар итү аеруча мөһим.

Укучыларның уку эшчәнлеген оештырганда, аларның фикерләү сәләтләре, үзләштерү мөмкинлекләре төрле булуын исәпкә алып, укытучы дәреслектә бирелгән эчтәлекне мөмкин кадәр дифференциальләштерергә, балаларның индивидуаль үзенчәлекләренә туры китереп, күнегүләр системасын планлаштырырга тиеш.

## Ишетеп аңлау күнегүләре

### Мәктәптә

### 1–3 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуками [ә], [ү], [ө].**
Бәйрәм, белем, кәеф, яхшы, уңыш, бүген, дәфтәр, көн.

**2. Прослушайте и укажите слова, обозначающие учебные предметы.**
Күлмәк, каләм, костюм, дәфтәр, бетергеч, бәйрәм, дәреслек, китап.

**3. Прослушайте и укажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**
1) Бу — дәфтәр. Бу дәфтәр миңа.
2) Бу — каләм. Бу каләм аңа.
3) Бу — китап. Бу китап сиңа.

**4. Прослушайте и скажите данные слова во множественном числе.**
Дәреслек, дәфтәр, китап, бетергеч, каләм.

**5. Прослушайте и укажите слова, обозначающие действия.**
Бәйрәм, котлый, яхшы, килә, бирә, бүген, яза, килешә, тели, ала.

**6. Прослушайте и закончите предложения.**
Мин сине бәйрәм белән ... . Сиңа уңышлар ... . Синең күлмәгең бик ... . Бу костюм сиңа ... .

## 4–6 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в каких есть звук (к).**

Укытучы, Казан, шакмаклы, кая, китап, мәктәп, кайда, дәрес, кем, кыз.

**2. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимения *минем (синең, аның).***

Мәктәп, китап, кәеф.

**3. Прослушайте и укажите, какие предложения говорят при встрече со взрослыми, а какие при встрече с друзьями и родными.**

Исәнмесез. Сәлам. Саумысыз. Исәнме. Сау бул. Сау булыгыз. Хуш. Хушыгыз.

**4. Прослушайте и укажите слова с ударением на первом слоге.**

Кая, рәхмәт, яхшы, кайчан, бәйрәм, кайдан, матур, сәлам, котлый, кайда.

**5. Прослушайте и измените предложения по образцу.**

*Образец: Марат кибеткә бара. — Марат кибеттән кайта.*

Айдар мәктәпкә бара. —

Алсу бакчага бара. —

Олег китапханәгә бара. —

## 7–8 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, обозначающие учебные предметы.**

Күлмәк, каләм, акбур, дәфтәр, бетергеч, кунак, дәреслек, китап.

**2. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимения *минем (синең, аның).***

Дәфтәр, китап, каләм, бетергеч.

**3. Прослушайте и определите количество слов в предложениях.**

1) Ленаның биш яңа китабы бар. 2) Бүген әни миңа яңа сумка алды. 3) Айдарга чиста дәфтәр кирәк. 4) Петяга дәфтәр кирәкми.

**4. Прослушайте и измените предложения по образцу.**

*Образец*: *Миңа дәфтәр кирәк — Миңа дәфтәр кирәк түгел. Миңа дәфтәр кирәкми.*

Сиңа чиста дәфтәр кирәк. —

Миңа сүзлек кирәк. —

Аңа күлмәк кирәк. —

**5. Прослушайте и скажите, что опущено во втором предложении каждой пары.**

Миңа биш дәфтәр кирәк. Миңа дәфтәр кирәк.

Коляга бер каләм кирәк. Коляга каләм кирәк.

Айнурга сигез китап кирәк. Айнурга китап кирәк.

**6. Прослушайте и скажите данные словосочетания во множественном числе.**

Буйлы дәфтәр, шакмаклы дәфтәр, матур көн, яңа китап, озын каләм.

## 9–11 нче дәресләр

**1. Прослушайте и расположите слова в нужном порядке.**

Бер, биш, алты, өч, ике, җиде, дүрт, тугыз, сигез, ун.

**2. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Миңа буйлы дәфтәр кирәк. Миңа шакмаклы дәфтәр кирәк.
2) Китапларны сумкага салам. Китапларны сумкадан алам.
3) Роза биш яңа дәфтәр алды. Роза өч яңа дәфтәр алды.

**3. Прослушайте и скажите, что опущено во втором предложении каждой пары.**

1) Мин озын карандашны сумкага салдым. Мин карандашны сумкага салдым.
2) Син зәңгәр карандашны сумкадан алдың. Син карандашны сумкадан алдың.

**4. Прослушайте и дайте утвердительный ответ по образцу.**

*Образец: Бу дәфтәрләр кызылмы? — Әйе, бу дәфтәрләр кызыл.*

Бу дәфтәр шакмаклымы?
Бу дәфтәр буйлымы?
Бу карандашлар кыскамы?
Бу карандашлар озынмы?

**5. Прослушайте и измените предложения по образцу.**
*Образец: Синең күлмәгең матур. — Сиңа күлмәк килешә.*
Синең костюмың матур. —
Синең сумкаң матур. —
Синең итәгең матур. —

## 12–13 нче дәресләр

**1. Прослушайте и определите количество слогов в каждом слове.**
Бара, сөйли, кайта, яза, ача, йөгерә, тыңлый, китә.

**2. Назовите слова, выражающие действия.**
Дежур, дәрес, килә, яза, алар, авырый, стадион, булыша, сала, куя, эшли.

**3. Прослушайте и измените слова по образцу.**
*Образец: бара-бар.*
Ала, килә, китә, сала, куя, эшли, укый, яза, сөйли, бара, кайта.

**4. Прослушайте и покажите действия в движениях.**
Йөгер, әйт, яз, укы, сөйләш, утыр, ал, куй.

## 14–16 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ә].**
Рәсим, укый, яза, сикерә, бирә, дәфтәр, дөрес, чишә.

**2. Прослушайте и укажите словосочетания, отвечающие на вопрос *нишләде?***
Китап укый, мисал чиште, күп сорады, тиз йөгерде, дөрес укый, тиз укыды, миңа булышты, матур язды.

**3. Прослушайте и измените слова по образцу.**

*Образец: йөри — йөрде.*

укый —
бара —
сикерә —
бирә —
яза —

**4. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Ренат китап укыды. Ренат китап алды.
2) Балалар китап укыдылар. Балалар әкият укыдылар.
3) Алсу биек сикерде. Алсу тиз сикерде.
4) Марат бишле алды. Марат өчле алды.

**5. Прослушайте и измените словосочетания по образцу.**

*Образец: Мин ачам. — Мин ачтым.*

Син куясың. —
Ул сөртә. —

### 17–19 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и расположите слова в нужном порядке.**

Бер, биш, алты, өч, ике, җиде, дүрт, тугыз, сигез, ун.

**2. Назовите слово, лишнее в логическом ряду.**

Бишле, икеле, берле, өчле, тугызлы, дүртле.

**3. Прослушайте и измените предложения по образцу.**

*Образец: Миңа дәрес ошый. Миңа дәрес ошады.*

Без диктант язабыз. Олег чиста яза. Мин хатасыз язам.

**4. Прочитайте диалог и скажите, сколько в нём вопросительных предложений.**

— Сез бүген диктант яздыгызмы?
— Әйе.

— Диктант авырмы?
— Юк. Җиңел.
— Син диктанттан ничәле алдың?
— Дүртле, чөнки минем бер хатам бар иде.

## 20–21 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите словосочетания, в которых есть звук [ә].**
Сорау бирә, җавап бирә, хата төзәтә, мәсьәлә чишә.

**2. Прослушайте и укажите словосочетания, отвечающие на вопрос *нишләде?***
Китап укый, мисал чиште, күп сорады, мәсьәлә чишә, тиз укыды, миңа булышты, матур язды.

**3. Прослушайте и измените слова по образцу.**
*Образец: Йөри — йөрде.*
укый —
билге ала —
чишә —
бирә —
җавап бирә —

**4. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**
1) Ренат китап укыды. Ренат китаплар укыды.
2) Балалар мисал чиштеләр. Балалар мәсьәлә чиштеләр.
3) Алсу ярдәм итте. Алсу ярдәм итмәде.
4) Марат бишле алды. Марат дүртле алды.

**5. Прослушайте и измените словосочетания по образцу.**
*Образец: Мин эшлим. — Мин эшләмим.*
1) Син чишәсең. —
2) Ул укый. —
3) Мин ярдәм сорыйм. —
4) Ул ярдәм итә. —

## 22–24 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ә].**
Килә, эшләми, укый, чөнки, ләкин, ярата, ошый, китап.

**2. Прослушайте и укажите слова с ударением на первый слог.**
Кабатлый, нишли, бирә, ошый, бармый, кайда, карамый, саный, ничә, телевизор.

**3. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нишләми?***
Язмый, эшли, тыңламый, кабатлый, сөйләми, котламый, бара, килми.

**4. Прослушайте и укажите, что добавлено во втором предложении.**
Бара. — Мәктәпкә бара.
Укый. — Китап укый.
Язмый. — Диктант язмый.
Бирми. — Дәфтәрне бирми.
Ярата. — Уйнарга яратмый.

**5. Назовите слово, лишнее в логическом ряду.**
Сайламый, укымый, килми, бара, язмый, сөйләми, котламый.

## 25–28 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ә̆].**
Саный, ун, егерме, сиксән, утыз, кырык, илле, җитмеш, җиде.

**2. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимения *минем (синең, аның).***
Китап, шигырь, атна, көн.

**3. Прослушайте и расположите слова в нужном порядке.**
Илле, егерме, алтмыш, сиксән, утыз, туксан, кырык, җитмеш, йөз, ун.

**4. Прослушайте и скажите, какие слова пропущены в логическом ряду.**
Беренче, икенче, өченче, ... , бишенче, ..., җиденче, ..., ..., унынчы.

## Көндәлек режим

### 29–31 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ч].**
Эчә, ничә, куя, ничәдә, кайта, китә, өч, йоклый.

**2. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нишли?***
Рәхмәт, кайта, китә, дәрес, ял, йоклый, әзерли, ашый.

**3. Прослушайте и измените слова по образцу.**
*Образец: Тора — торды.*
Ясый, юа, тора, куя, хәзерли, керә, карый, тыңлый.

**4. Прослушайте и укажите предложения, в которых действия уже произошли.**

1) Иртәнге ашны мин сәгать 7 дә ашадым. 2) Көндезге ашны Алсу сәгать 12 дә ашый. 3) Кунаклар кичке сәгать 6 да килделәр. 4) Айгөлнең әнисе тәмле коймак пешерә.

**5. Прослушайте и расположите цифры в нужном порядке.**
12, 10, 20, 13, 15, 19, 17, 11, 14, 16, 18.

### 32–34 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ә].**
Йоклый, эчә, тора, өй, җырлый, сикерә, әзерли.

**2. Прослушайте и измените предложения по образцу.**
*Образец: Мин тордым һәм ашадым. — Мин тордым да ашадым.*
Оля торды һәм чәй эчте.
Марат өйгә кайтты һәм телевизор карады.
Гүзәл дәрес әзерләде һәм урамга китте.

**3. Прослушайте и скажите, сколько предложений в тексте.**

Мин йокыдан тордым һәм чәй эчтем. Урынны җыештырдым да мәктәпкә киттем. Мәктәптә укыдым, яздым, җырладым. Кич өйгә кайттым.

**4. Назовите составное слово, лишнее в логическом ряду.**
Иртәнге аш, токмачлы аш, кичке аш, көндезге аш.

**5. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**
1) Мин сәгать алтыда йокыдан тордым. Мин сәгать җидедә йокыдан тордым.
2) Рөстәм сәгать бердә өйгә кайта. Рөстәм сәгать икедә өйгә кайта.
3) Алсу сәгать тугызда йокларга ята. Алсу сәгать унда йокларга ята.

## Ашханәдә

### 35–37 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ŏ].**
Дөге, кәбестә, ботка, солы, аш, пешекче, тәмле, токмач, кәбестә, карабодай, ашханә.

**2. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**
1) Аш. Токмачлы аш.
2) Мин кәбестә ашы яратам. Мин дөге ашы яратам.
3) Карабодай боткасы белән котлет бик тәмле. Дөге боткасы белән котлет бик тәмле.

**3. Назови слово, лишнее в логическом ряду.**
Дөге боткасы, токмачлы аш, карабодай боткасы, ашыйм, кәбестә ашы, котлет.

**4. Укажите предложения, в которых выражен отрицательный ответ.**
— Син иртәнге ашны ашханәдә ашыйсыңмы?
— Юк, мин иртәнге ашны өйдә ашыйм.
— Көндезге ашны да өйдә ашыйсыңмы?
— Юк, көндезге ашны мин ашханәдә ашыйм.

**5. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимения *минем (синең, аның).***
Кашык, чәй, тәлинкә.

## 38–40 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ө].**
Ашханә, рәхмәт, дөге, көндез, чәкчәк, өчпочмак, гөбәдия, ит.

**2. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ч].**
Эчә, юа, урындык, куя, чәй, кашык, чәнечке, тәлинкә, пычак.

**3. Прослушайте и укажите слова с мягкими гласными звуками.**
Гөбәдия, бәлеш, алма, сыер, тавык, ит, пилмән, чәкчәк, коймак, ипи.

**4. Назови слово, лишнее в логичеком ряду.**
Аш, тәмле, гөбәдия, алма, пирог, токмачлы аш, чәкчәк.

**5. Прослушайте и скажите данные слова во множественном числе.**
Пешекче, кыстыбый, ашханә, йомырка, пирог, коймак.

**6. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Пешекче апалар тәмле пешерәләр. Пешекче апалар тәмле пешермиләр.
2) Минем әнием аш пешерә. Минем әнием өчпочмак пешерә.
3) Айдар йомырка ярата. Айдар пилмән ярата.

## Без әти-әниләргә булышабыз

## 41–42 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звуки [йа]**
Гаилә, тату, сөя, эшчән, ял итә, ята, ярата, бик.

**2. Прослушайте и укажите слова с мягкими гласными звуками.**
Дәү әти, эш, барыбыз, өй, кеше, абый, бабай, тату, зур, кечкенә.

**3. Назовите слово, лишнее в логическом ряду.**
Бакча, нефтьче, бакчачы, эшче.

**4. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Безнең гаилә тату. Безнең гаилә тату түгел.
2) Минем дустым эшчән. Минем дустым ялкау.
3) Без өйдә дүрт кеше. Без өйдә биш кеше.

**5. Прослушайте диалог. Сколько в нем вопросительных предложений?**

— Сезнең гаилә зурмы?
— Бик зур түгел.
— Гаиләдә сез ничә кеше?
— Гаиләдә без дүрт кеше: әти, әни, абый һәм мин.
— Сезнең гаилә татумы?
— Әйе, бик тату.

### 43–45 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ә].**
Әни, кыз, укучы, гаилә, кеше, балалар, кечкенә.

**2. Прослушайте и укажите слова с твёрдым произношением.**
Бабай, файдалы, урын, үзе, җыя, тәмле, тора, ясый, энем.

**3. Прослушайте и укажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Безнең гаилә зур. Безнең гаилә бик зур.
2) Мин иртә торам. Мин бик иртә торам.

**4. Прослушайте и укажите слова, обозначающие действия.**
Шатлана, җыя, файдалы, тәмле, мактый, юына, кия.

### 46–48 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [а$^{o}$].**
Әби, кайчан, дөрес, матур, яхшы, тырыш, эш, янында, гөл, аш.

**2. Прослушайте и укажите слова мягкого произношения.**
Әни, була, әби, дәү, пешерә, түгел, барыбыз, матур.

**3. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нинди?***
Тәмле, нурлы, пешерә, ямьле, матур, гөл, аш.

**4. Прослушайте и укажите, что пропущено во втором предложении каждой пары.**

1) Мин иртән зарядка ясыйм. Мин зарядка ясыйм.
2) Мин әбиемә, әниемә, әтиемә, бабама булышам. Мин әбиемә, әниемә, әтиемә булышам.

**5. Прослушайте и укажите вопросительные предложения.**

1) Мин тиз киенәм.
2) Син кайчан зарядка ясыйсың?
3) Син иртән чәй эчәсеңме?
4) Айдар — бик яхшы малай.

**6. Прослушайте и повторите предложения по порядку стихотворения «Дәү әнием».**

1) Барыбыздан олы ул.
2) Әниемнең әнисе — ул минем дәү әнием.
3) Матур гөлләр үстерә.
4) Тәмле ашлар пешерә.
5) Өебезнең нуры ул.

## Туган көн — күңелле бәйрәм

### 49–50 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ә].**
Әдәп, сау бул, хәерле көн, тәмле, туган көн, әйбәт, сәлам.

**2. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимения *минем (синең, аның).***
Туган көн, чәчәк, котлау.

**3. Прослушайте и назовите слова, выражающие действия.**
Котлый, килә, рәхмәт, сайлый, чакыра, сәлам, хәерле.

**4. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**
1) Хәерле көн. Хәерле кич.
2) Чакыр әле. Чакырыгыз әле.
3) Әйт әле. Әйтегез әле.
4) Туган көн якшәмбе була.Туган көн шимбә була.
5) Туган көн сәгать уникедә була. Туган көн сәгать икедә була.
6) Туган көнгә мин чәчәк алам.Туган көнгә мин китап алам.

**5. Прослушайте диалог и скажите, о чём идёт речь.**
— Айрат, исәнме!
— Сәлам, Марат!
— Якшәмбе синең вакытың бармы?
— Әлбәттә.
— Мин сине туган көнгә чакырам.
— Сәгать ничәдә?
— Көндезге сәгать бердә.
— Ярый, киләм.
— Яхшы, көтәм.

**51–55 нче дәресләр**

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ы].**
Котлый, юа, шалтырый, чишенә, табын, мөмкин, эчә, өчпочмак.

**2. Прослушайте и укажите слова мягкого произношения.**
Күңелле, җырлый, уйный, тәмле, кечкенә, бүләк, рәхмәт.

**3. Прослушайте и измените слова по образцу.**
*Образец: Укый — укыды.*
Юа, утыра, чишенә, эчә, була, уйный, җырлый, килә.

**4. Прослушайте диалог и расскажите содержание.**

— Хәерле кич!

— Исәнмесез! Керегез! Түргә узыгыз.

— Нинди матур табын!

— Өчпочмак ашагыз! Чәй эчегез!

— Рәхмәт! Бик тәмле булды.

**5. Прослушайте и укажите, что изменилось во втором предложении каждой пары.**

1) Мин апамны туган көне белән котлыйм. Мин абыемны туган көне белән котлыйм.

2) Мин дустыма шалтыраттым. Мин әбиемә шалтыраттым.

3) Алсу кунакта тәмле пирог ашады. Алсу кунакта тәмле өчпочмак ашады.

## Яраткан уеннарым

### 56-61 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [қ].**

Салкын, болын, салкын, саф, йомшак, ак, кар, куна, бөртек.

**2. Прослушайте и, если не согласны, дайте отрицательный ответ.**

Кыш көне салкын, кар ява, җир ап-ак. Кышын көннәр озын, төннәр кыска. Март, апрель, май — кыш айлары.

**3. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ч].**

Тау, чана, төньяк, һава, салкын, чаңгы, җил, кыш, аяз, чыга, көндез, төнлә.

**4. Прослушайте и укажите слова с твердыми окончаниями.**

Бара, шуа, ява, ясый, тыңлый, китә, килә.

**5. Назовите слово, лишнее в логическом ряду.**

Салкын, җылы, матур, ак, бүген, аяз, җилле, саф.

**6. Прослушайте диалог и скажите, о чем идёт речь.**

— Сәлам, Айгөл.
— Сәлам, Аня.
— Айгөл, әйдә урамга чыгабыз.
— Урамда салкынмы?
— Юк, җил юк. Кар гына ява.
— Ярар, урамда бик рәхәт икән.

**7. Прослушайте и назовите слово, лишнее в логическом ряду.**

Чаңгы шуа, чана шуа, су коена, кар бабай ясый.

**8. Прослушайте и продолжите предложения.**

Мин тауга ... . Син тауга ... . Ул тауга ... .

**9. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Сәлим урамга чыкмады. Сәлим урамга чыкмады, өйдә утырды.
2) Малайларга бик күңелле булды. Малайларга бик күңелсез булды.

## 62–65 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ө].**

Киләм, йөзәм, су коенам, йөрим, керәм, уйныйм, яратам, көләм.

**2. Прослушайте и назовите слово, лишнее в логическом ряду.**

Киләм, йөзәм, су коенам, елга, керәм, уйныйм, яратам, көләм.

**3. Прослушайте текст и расскажите содержание.**

Бүген Айдар белән Петя бик озак шашка уйнадылар. Айдар 3 тапкыр җиңүче булды, ә Петя 2 тапкыр җиңүче булды.

**4. Прослушайте и измените предложения по образцу.**

*Образец*: *Мин велосипедта йөрим.— Син дә йөрисеңме ?*
Мин шахмат уйныйм. —
Мин шашка уйныйм. —
Мин футбол уйныйм. —
Мин баскетбол уйныйм. —
Мин теннис уйныйм. —

**5. Прослушайте и скажите, что опущено во втором предложении каждой пары.**

1) Айдар бик яхшы йөзә. Айдар яхшы йөзә.
2) Петя бик яхшы уйный. Петя яхшы уйный.

## Шәһәрдә һәм авылда

### 66–71 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ә].**
Казан, Әлмәт, Яр Чаллы, Бөгелмә, Алабуга, Минзәлә, Түбән Кама, Буа.

**2. Прослушайте и укажите слова мягкого произношения.**
Шәһәр, йорт, урам, бара, Әгерҗе, яши, кунак, килә, фатир, бүлмә.

**3. Прослушайте и продолжите предложения.**

1) Әлмәт — ...
2) Казан — ...
3) Яр Чаллы, Алабуга, ...

**4. Прослушайте диалог и скажите, сколько в нем вопросительных предложений.**

— Син кайда яшисең?
— Мин Яр Чаллы шәһәрендә яшим.
— Ә нинди урамда торасың?
— Шамил Усманов урамында.
— Сезнең фатирыгыз ничәнче катта?
— Икенче катта.

**5. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Безнең шәһәр зур. Безнең шәһәр кечкенә.
2) Бу шәһәрнең урманнары тар, йортлары кечкенә. Бу шәһәрнең урамнары киң, йортлары зур.
3) Мин мәктәпкә автобус белән барам. Мин мәктәпкә трамвай белән барам.

**6. Прослушайте диалог и расскажите содержание.**

— Азат, син җәй көне кая барасың?
— Казанга.
— Кем белән?
— Әни белән. Ә син кая барасың?
— Чистайга.
— Чистайда кемнәр яши?
— Минем әбием, бабам Чистайда яшиләр.

## 72–77 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [қ].**

Бүлмә, йокы, аш бүлмәсе, шкаф, диван, яңа, яшел, кызыл, күңелле.

**2. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимения *минем (синең, аның).***

Әни, әти, бүлмә, абый.

**3. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Мин Чаллыда яшим. Мин Казанда яшим.
2) Алсу икенче катта тора. Алсу өченче катта тора.
3) Безнең фатирда 2 бүлмә. Безнең фатирда 3 бүлмә.
4) Фатирда кунак бүлмәсе, йокы бүлмәсе бар. Фатирда кунак бүлмәсе, йокы бүлмәсе, аш бүлмәсе бар.
5) Фатирда диван, телевизор бар. Фатирда диван, телевизор, шкаф бар.

**4. Прослушайте текст и укажите слова, отвечающие на вопрос *нинди?***

Безнең фатир зур, яңа. Фатирда матур диван, түгәрәк өстәл, биек шкаф бар. Безнең пәрдәләр ак төстә.

## 78–81 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуками [а̊], [ә].**

Авыл, яши, урам, матур, йорт, бакча, янында, алма, чия, агач, үсә, бәрәңге, үлән, яңа, мәктәп, чәчәк, җиләк-җимеш, уйный.

**2. Прослушайте слова и укажите движениями, как вы их понимаете.**

Алдында, артында, янында, эчендә.

**3. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Безнең урам бик матур. Безнең урамдагы йортлар бик матур.

2) Бакчада алмалар, чияләр һәм башка агачлар үсә. Бакчада алмалар, чияләр, юкәләр һәм башка агачлар үсә.

3) Мәктәп алдында җиләк-җимешләр, чәчәкләр үсә. Мәктәп алдында һәм артында җиләк-җимешләр, чәчәкләр үсә.

**4. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимения *минем (синең, аның).***

Авыл, урам, йорт, бакча, мәктәп.

**5. Прослушайте и скажите, сколько предложений в тексте.**

Мин шәһәрдә яшим. Җәй саен авылга кунакка кайтам. Авылда минем әбием яши. Авылда бик рәхәт.

## Милли бәйрәмнәр

### 82–86 нчы дәресләр

**1. Прослушайте ряд слов и постарайтесь правильно повторить.**

Калфак, түбәтәй, камзул, читек, алъяпкыч.

**2. Прослушайте и укажите слово со звуком [w].**

Бәйрәм, иң, зур, төрле, кызык, Сабантуй, чүлмәк, вата, көрәшә.

**3. Прослушайте и определите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Сабантуй — Татарстанда зур бәйрәм. Сабантуй — Татарстанда иң зур бәйрәм.

2) Сабантуйда төрле уеннар уйныйлар. Сабандуйда төрле кызыклы уеннар уйныйлар.

3) Сабантуй бик матур урында була. Сабантуй бик матур урында, болында була.

**4. Прослушайте и найдите словосочетание, логически не связанное с другими.**

Чүлмәк вату, китап уку, атлар чабышы, баганага менү.

**5. Прослушайте и закончите предложения.**

Сабантуй бик матур ... . Ул июньдә ... . Сабантуйда кешеләр бәйрәмчә ... . Сабантуйда төрле кызыклы уеннар ... .

**6. Прослушайте и выберите правильный по смыслу вариант в каждой паре.**

1) Сабантуй — Татарстанда иң зур бәйрәм. 8 нче Март — Татарстанда иң зур бәйрәм.

2) Сабантуй болында үтә. Сабантуй урманда үтә.

3) Сабантуй август аенда була. Сабантуй июнь аенда була.

**7. Прослушайте и измените слова по образцу.**

*Образец: килә — килми*; *килде — килмәде.*

Катнаша, була, үтә, киенә, вата, көтә, көрәшә, йөгерә.

**87–91 нче дәресләр**

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [қ].**

Күңелле, бәйрәм, кыш көне, була, коймак.

**2. Прослушайте и назовите слово, лишнее в логическом ряду.**

Күңелле, бәйрәм, кыш көне, су коенам, коймак, пешерәләр, көн.

**3. Прослушайте текст и расскажите содержание.**

Масленица бәйрәме — күңелле бәйрәм. Ул кыш көне була. Бәйрәмдә коймак пешерәләр, кунакка баралар, бииләр, җырлыйлар.

**4. Прослушайте диалог и поговорите с другом.**

ә) — Фәридә, син кая барасың?
— Масленица бәйрәменә барам.
— Кем белән барасың?
— Дуслар белән барам.

— Бәйрәм сәгать ничәдә башлана?
— Бәйрәм сәгать унда башлана.

**5. Прослушайте и измените предложения по образцу.**
*Образец*: *Мин бәйрәмгә барам.— Син дә бәйрәмгә барасыңмы ?*
Мин Масленица бәйрәменә барам. —
Мин Сабантуй бәйрәменә барам. —
Мин Нәүруз бәйрәменә барам. —

**6. Прослушайте и укажите правильное утверждение.**
1) Масленица бәйрәме кыш көне була. Масленица бәйрәме җәй көне була.
2) Масленица бәйрәмендә коймак пешерәләр, кунакка баралар. Масленица бәйрәмендә бәлеш пешерәләр, кунакка баралар.
3) Нәүрүз — язны каршылау бәйрәме. Нәүрүз — көзне каршылау бәйрәме.
4) Бәйрәмнең хуҗасы — Кыш бабай. Бәйрәмнең хуҗасы — Нәүрүзбикә.

## Кечкенә дусларыбыз

## 92–102 нче дәресләр

**1. Прочитайте и укажите слова со звуком [и].**
Песи, эт, ярата, тәмле, ишетә, бирә, күз, акыллы, үти, исем.

**2. Прослушайте и укажите трёхсложные слова.**
Йөгерә, ишетә, тычкан, кәҗә, әтәч, солы, акыллы, карый.

**3. Прослушайте и укажите слово, лишнее в логическом ряду.**
Ак, кызыл, сары, зәңгәр, песи, күк, кара.

**4. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нинди?***
Көчле, матур, сөяк, азык, акыллы, хәйләкәр, тәмле, сөт.

**5. Прослушайте и укажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Бер йортта песи, эт, әтәч яшиләр. Бер йортта песи, эт, әтәч, кәҗә яшиләр.

2) Песи сөт ярата. Песи сөт, тычкан ярата.

3) Эт ит ярата. Эт ит, сөяк ярата.

**6. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя подходящие местоимения *мин, син, ул, без*.**

... яратам, ... бирә, ... уйныйбыз, ... юдык, ... үтисең.

**7. Прослушайте и найдите антонимы к этим словам.**

Тырыш, күп, тәмле, матур, акыллы, кечкенә.

**8. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Миңа этләр ошый, чөнки ... .

2) Миңа песиләр ошый, чөнки ... .

## Федераль эш программасына нигезләнгән календарь-тематик план

| Дәрес саны | Тема | Дәреснең коммуникатив максаты | Лексика |
|---|---|---|---|
| **Мәктәптә. (28 сәгать)<br>III Мир вокруг меня** | | | |
| 1–3 | Без мәктәпкә барабыз.<br>*Син, сез* зат алмашлыкларының төшем килеше формасы. «Беренче сентябрь — Белем бәйрәме» | Беренче сентябрь — Белем бәйрәме турында сөйли, укытучыны, дустыңны бәйрәм белән котлый белү.<br>Комплиментлар әйтә белү.<br>Ничәнче сменада, сыйныфта укыганыңны, кем белән утырганыңны әйтә белү | Белем бәйрәме<br>яңа уку елы<br>башлана<br>хөрмәтле<br>котлыйм<br>уңышлар<br>телим<br>килешә |
| 4–5 | Исемнең юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килеше формалары.<br>Татарстан шәһәрләрендә | Мәктәпкә барганны, мәктәптә укыганны, мәктәптән кайтканны әйтә белү | Татарстандагы шәһәр атамалары |
| 6–7 | *Мин ,син, ул* зат алмашлыкларының юнәлеш килеш формасы | Уку-язу әсбапларының барлыгын, юклыгын, кирәклеген, санын әйтә белү (сорау); үзеңә сорап алу, иптәшеңә тәкъдим итү | китап<br>дәфтәр<br>каләм<br>өстәл<br>бетергеч<br>кирәк — кирәкми<br>түгел<br>бир әле |
| 8–9 | Микъдар һәм тәртип саннары.<br>(1 дән 100 гә кадәр саннар).<br>«Сан + исем», «сан + сыйфат + исем» төзелмәләре | Предметларның санын, төсен кулланып, үзеңә сорый белү (*Миңа биш кызыл каләм бир әле*).<br>Портфельгә (сумкага) нәрсә салганыңны, сумкада (партада) нәрсә барлыгын, сумкадан нәрсә алганыңны әйтә, сорый белү | төсләр<br>нинди<br>шакмаклы<br>буйлы<br>озын<br>кыска<br>алам<br>салам |
| 10–11 | Исем.<br>Татар телендә *кем? нәрсә?* сораулары.<br>Исемнәрнең I, II, III зат берлек санда тартым белән төрләнеше | Татар телендә *кем? нәрсә?* сорауларын предметларга карата дөрес куллана белү.<br>Уку-язу әсбапларының барлыгын, юклыгын әйтә, сорый белү.<br>Бер-береңә комплимент әйтә белү | шат<br>бик<br>ничек |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 12–13 | Хәзерге заман хикәя фигыль.<br>*Без нәрсәләр эшлибез?* | Фигыльнең хәзерге заман формасын кулланып, нишләвең турында әйтә, иптәшеңнән сорый белү | ач<br>тор<br>куй<br>тыңла<br>ят<br>бүген<br>иртәгә<br>кичә |
| 14–16 | Билгеле үткән заман хикәя фигыль.<br>Без дәрестә.<br>*Бүген, иртәгә, кичә* — вакыт рәвешләре | Фигыльнең билгеле үткән заман формасын кулланып, нишләгәнең турында әйтә, иптәшеңнән сорый белү.<br>Вакыт рәвешләрен һәм заман формаларын кулланып, кайчан нишләгәнеңне әйтә, иптәшеңнән сорый белү | |
| 17–19 | *Чөнки*, *ләкин* теркәгечләре.<br>«Без диктант яздык» тексты.<br>Сыйфат ясагыч кушымчалар — *-лы/-ле, -сыз/-сез* | Диктант язганны сорый, әйтә белү.<br>Үзеңнең, иптәшеңнең нинди билге алганын, диктантта хата барлыгын, юклыгын әйтә белү. | билге<br>ничәле?<br>бишле, дүртле<br>математикадан<br>нокта<br>өтер<br>сорау<br>җиңел<br>авыр<br>хаталы<br>хатасыз |
| 20–21 | Татар телендә сингармонизм законы.<br>*Чөнки*, *ләкин* теркәгечләре.<br>«Чын иптәш» хикәясе | Дәрестә уку хезмәте турында сорый, әйтә белү.<br>Хикәяне сәнгатьле укый белү | хикәя укый<br>сорау бирә<br>мисал эшли<br>мәсьәлә чишә |
| 22–24 | Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең юклык формасы.<br>«Чын иптәш» хикәясен сөйли белү.<br>*Миңа ярдәм ит әле!* | Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең юклык формасын сөйләмдә куллану.<br>Үзеңә ярдәм сорый белү | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 25–27 | Микъдар һәм тәртип саннары. (100 дән 1000 гә кадәр саннар). Г. Зәйнашеваның «Бер атнада ничә көн?» шигыре | Саннар кулланып, ничә предмет барлыгын, кирәклеген, ничәнче рәттә, партада утырганыңны әйтә; атна көннәрен дөрес тәртиптә әйтә белү | 100 дән 1000 гә кадәр микъдар һәм тәртип саннары |
| 28 | Кабатлау дәресе | | |
| **Көндәлек режим. (6 сәгать)**<br>**I Мир моего «Я»** | | | |
| 29–31 | Сәгать ничә? | Вакытны әйтә, сорый белү. | Сәгать ничәдә?<br>кайчан?<br>йокыдан тора<br>дәрес әзерли |
| 32–33 | Минем көндәлек режимым | Үзеңнең көндәлек режимың турында сөйли белү. Кайчан нәрсә эшләгәнеңне әйтә белү | көндәлек режим<br>иртәнге аш<br>көндезге аш<br>кичке аш |
| 34 | Кабатлау дәресе | | |
| **Ашханәдә. (6 сәгать)**<br>**III Мир вокруг меня** | | | |
| 35–37 | Ашханәдә. «Ашханәдә» тексты. Без хикәя сөйлибез | Ашханәдә ашаганны, ашханәдә нәрсә пешергәнне, нинди ашлар яратканны әйтә белү. Ашларны сорап ала белү | ашханә<br>кәбестә ашы<br>токмачлы аш<br>ботка<br>пешекче<br>кесәл<br>иртәнге аш<br>көндезге аш<br>кичке аш |
| 38–39 | Без нинди ризык-лар яратабыз? *-лы/-ле, -сыз/-сез* сыйфат ясагыч кушымчалары | Дустыңның нинди ризыклар яратканын сорый, ашханәгә бергә барырга тәкъдим итә белү. Кунакларны каршы ала, табынга чакыра белү | чәкчәк<br>өчпочмак<br>бәлеш<br>кыстыбый<br>гөбәдия<br>баллы - балсыз<br>тәмле - тәмсез<br>итле - итсез |
| 40 | Кабатлау дәресе | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Без әти-әниләргә булышабыз. (8 сәгать)<br>I Мир моего «Я»** | | | |
| 41–42 | Г. Тукайның «Безнең гаилә» шигыре.<br>*-чы/-че* — исем ясагыч кушымчалар.<br>*Минем әти — төзүче* | Гаиләдә кемнәр барлыгын, бергә нишләвегез турында әйтә белү. Гаилә әгъзаларының кем булып эшләүләре турында әйтә белү | төзүче<br>эшче |
| 43–45 | «Акыллы малай» тексты.<br>*Ни өчен?* соравы; *чөнки, шуңа күрә* теркәгечләре.<br>*Әти-әниләргә булышабыз* | Өйдә нәрсәләр эшләгәнне сорый, әйтә белү.<br>Әти-әниләргә ничек булышканны сорый, әйтә белү.<br>*Ни өчен?* соравын куя, аңа җавап бирә белү. Дустыңа өй хезмәтендә булышырга тәкъдим итә белү.<br>Эш куша белү.<br>Энеңне, сеңлеңне өй хезмәтендә булышканы өчен мактый белү | акыллы<br>иртән<br>урын җыя<br>зарядка<br>ясый<br>файдалы<br>аннан соң<br>киенә<br>булыша |
| 46–47 | «Без өйдә булышабыз» темасына сөйләшү.<br>Мин әбигә булышам.<br>Ә. Бикчәнтәеваның «Дәү әнием» шигыре | | Син яхшы кыз (малай)! Син акыллы! Син әйбәт! |
| 48 | Кабатлау дәресе | | |
| **Туган көн — күңелле бәйрәм. (7 сәгать)<br>I Мир моего «Я»** | | | |
| 49–50 | Тәмле сүзләр.<br>Телефоннан әдәпле сөйләшү | Әдәпле сөйләшә белү өлгеләре белән танышу.<br>Телефоннан әдәпле сөйләшә белү | |
| 51–53 | Туган көнгә чакыру.<br>Туган көн — күңелле бәйрәм.<br>Табын янында | Туган көнгә әдәпле чакыра белү.<br>Туган көнгә бүләк алып килгәнне әйтә белү, котлый белү. Бер-береңне табынга чакыра, кыстый, ашаганнан соң рәхмәт әйтә белү | бүләк<br>бәлеш<br>гөбәдия<br>чәкчәк<br>өчпочмак<br>тагын |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 54–55 | Кабатлау дәресләре | | |
| **Яраткан уеннарым. (10 сәгать)**<br>**II Мир моих увлечений** | | | |
| 56–58 | Кыш билгеләре.<br>Сыйфат.<br>Сыйфатларның чагыштыру дәрәҗәсе.<br>Урамга уенга чакыру.<br>«Тауда» хикәясе.<br>Без хикәя язабыз | Кыш билгеләрен әйтә белү. Кышкы уен төрләрен әйтә, урамга уенга чакыра белү.<br>Тауга барганыңны, кайтканыңны, тауда чаңгы шуганыңны әйтә белү.<br>Хикәяне сөйләү. Хикәя язу | һава торышы<br>аяз<br>болытлы<br>көчле җил исә |
| 59–61 | «Дима, Азат, Әмир — дуслар» тексты | Урамга уенга чакыра белү.<br>Кышкы уен төрләрен әйтә, уенга чакыра; тауга барганыңны, кайтканыңны, тауда чаңгы шуганыңны әйтә белү | кышкы уен төрләре<br>тау<br>шугалак<br>чана шуа<br>чаңгы, тимераяк |
| 62–64 | Без шахмат, шашка уйныйбыз.<br>Без футбол, баскетбол, теннис уйныйбыз.<br>Җәйге уеннар | Шахмат, шашка, футбол, баскетбол теннис уйнау турында, җәйге уеннарга чакырып, диалоглар төзү | |
| 65 | Кабатлау дәресе | | |
| **Шәһәрдә һәм авылда. ( 16 сәгать)**<br>**III Мир вокруг меня** | | | |
| 66–68 | Без Татарстанда яшибез.<br>«Исем+ тартымлы исем» сүзтезмәләр | Үзеңнең, иптәшеңнең кайда яшәгәнлеге турында әйтә, сорый белү.<br>Татарстан шәһәрләрен, башкаланы атый белү.<br>Үзең яшәгән шәһәрең турында әйтә, сорый белү.<br>Шәһәргә, авылга нинди транспорт белән барганыңны әйтә, иптәшеңнән сорый белү | яши<br>тора<br>елга<br>күл<br>Казан шәһәре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 69–71 | Мин шәһәрдә яшим | Үзеңнең кайда яшәгәнлегең, иптәшеңнең кайда яшәгәнлеге турында әйтә, сорый белү. Үзең яшәгән шәһәр турында әйтә, дустыңнан сораша белү | тора<br>яши<br>Бауман урамы |
| 72–74<br>75–77 | Безнең йорт.<br>Безнең фатир | Үзең яшәгән урам, йорт, фатир турында әйтә белү | йорт<br>бүлмә<br>ничәнче фатир<br>ничәнче кат<br>йокы бүлмәсе<br>аш бүлмәсе<br>кунак бүлмәсе |
| 78–80 | Мин авылда яшим. *Янында, артында, алдында* бәйлек сүзләре | Үзеңнең кайда яшәгәнлегең, иптәшеңнең кайда яшәгәнлеге турында әйтә, сорый белү.<br>Мәктәп, йорт янында нәрсәләр барын әйтә белү.<br>Каникулда кая барганлыгың турында сөйли белү | авыл<br>өй янында<br>(артында, эчендә, алдында)<br>һәр<br>барлык |
| 81 | Кабатлау дәресе | | |
| **Милли бәйрәмнәр. (10 сәгать)<br>IV Моя Родина** | | | |
| 82–83 | Без — төрле милләт балалары | Үзең яшәгән төбәктә нинди милләтләр барлыгы, нинди телләрдә сөйләшүләре турында әйтә, сорый белү.<br>Татар милли киемнәрен атый белү | русча<br>татарча<br>калфак<br>түбәтәй<br>камзул<br>читек<br>алъяпкыч |
| 84–86 | Сабантуй уеннары. Без Сабантуйга барабыз.<br>Җыйнак һәм җәенке җөмләләр.<br>Гади җөмләләрдә сүз тәртибе | Сабантуйга бару, Сабантуй уеннары, бәйрәмдә катнашу турында сөйли, дустыңнан сораша белү | уен, чүлмәк вату, баганага менү, көрәш |
| 87–88 | Нәүрүз — язны каршылау бәйрәме.<br>Нәүрүз бәйрәмендәге уеннар | Нәүрүз — язны каршылау бәйрәме икәне турында, бәйрәмдә нишләүләре турында сөйләшү | күңел ачу<br>Бәйрәм хуҗасы — Нәүрүзбикә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 89–90 | Масленица бәйрәме — күңелле бәйрәм. | Милли бәйрәмнәрне атый белү. Масленица бәйрәме турында сөйләшә белү | Масленица бәйрәме, Раштуа, Пасха, Ураза бәйрәме |
| 91 | Кабатлау дәресе | | |
| **Кечкенә дусларыбыз. (11 сәгать)<br>II Мир моих увлечений** | | | |
| 92–94 | Минем этем бар. Этемнең гадәтләре | Үзеңнең этең, аның кыяфәтен һәм гадәтләрен сөйли белү | каршы ала командалар үти |
| 95–97 | Минем песием бар. Сыйфатларның чагыштыру дәрәҗәсе | Үзеңнең этең, аның кыяфәтен һәм гадәтләрен сөйли белү.<br>Үзеңнең песиең, аның кыяфәтен һәм гадәтләрен сөйли белү | Үзеңнең песиең, аның кыяфәтен һәм гадәтләрен сөйли белү |
| 98–102 | «Кем нәрсә ярата?» әкияте буенча сөйләшү | «Кем нәрсә ярата?» әкияте буенча сөйләшү. «Кем нәрсә ярата?» әкиятен сөйли белү | |

## 3 нче сыйныф укучыларының татар теле буенча белем дәрәҗәләрен билгеләү үрнәкләре

### Мәктәптә

**1. Переведи данные слова и словосочетания.**
Белем бәйрәме, яңа уку елы, уңыш, котлыйм, телим, бетергеч, шакмаклы, тәнәфес, дәрес, такта, акбур.

**2. Поздравь учительницу с праздником 1-го сентября.**

**3. Выбери правильное окончание.**
Мин укытучы... (кемгә?) чәчәк бүләк иттем.
а) -не; б) -га; в) -дан; г) -ны.

**4. Спроси соседа по парте:**
а) есть ли у него тетрадь, цветные карандаши;
б) где находятся его книги, сумка, тетрадь.

**5. Скажи маме, что у тебя нет ручки, тетради, линейки. Попроси маму купить тетради в линейку и в клетку.**

**6. Допустим, ты дежурный в классе. Сообщи учителю какое сегодня число, кого нет в классе.**

**7. Сообщи другу о том, что:**
— сегодня у вас пять уроков;
— у вас была контрольная работа;
— вы писали диктант.

**8. Спроси у подруги:**
— сделала ли она домашнее задание;
— что им задали на дом;
— какие оценки она получила сегодня.

**9. Переведи предложения.**

1) Я часто хожу в библиотеку, потому что люблю читать книги.
2) Дома я прочитал рассказ и решил задачу.

## Көндәлек режим

**1. Переведи словосочетания и составь с ними предложения.**

В семь часов, в два часа, в девять часов, во сколько часов?

**2. Какие глаголы запишешь вместо точек, если указанные действия не происходят?**

1) Әти зарядка ясый, ә ул ... .
2) Син салкын су белән юынасың, ә ул ... .
3) Мин әнигә булышам, ә ул ... .
4) Дустым иртән чәй эчә, ә ул ... .

**3. Составь вопросы к предложению.**

Әтием иртән салкын су белән юына.

**4. Какие окончания поставишь, если действия уже произошли?**

1) Алсу әнигә булыш... . 2) Марат зарядка яса... . 3) Укучы матур сөйлә... .

**5. Представь, что эти действия не произошли. Как изменятся глаголы?**

Айдар иртән тора, зарядка ясый, салкын су белән юына. Аннан соң чәй эчә һәм мәктәпкә китә.

**6. Спроси друга, во сколько часов он:**

— встал;
— пришёл в школу;
— вернулся из школы;
— сделал уроки;
— помогал маме;
— играл на улице.

**7. Вставь пропущенные реплики в диалог.**
— ... ?
— Мин сәгать җидедә йокыдан торам.
— ... ?
— Әйе, мин иртән зарядка ясыйм.
— ... ?
— Мәктәпкә дустым белән барам.

**8. Расскажи о своём режиме дня по вопросам:**
1) Син иртән нишлисең?
2) Сәгать ничәдә мәктәпкә китәсең?
3) Сәгать ничәдә мәктәптән кайтасың?
4) Өйдә нишлисең?
5) Сәгать ничәдә дәрес әзерлисең?

## Ашханәдә

**1. Переведи данные слова и словосочетания и запиши их в транскрипции.**

Столовая, суп с лапшой, рисовая каша, гречневая каша, овсяная каша, повар, пью, кушаю, вкусный, горячий, холодный, варит.

**2. Вместо точек вставь нужные окончания.**
1) Оля, икмәк... тәлинкә... куй әле.
2) Катя, Петя, өстәл яны... килегез.
3) Айдар, урындык... өстәл яны... куй.
4) Алсу, чәнечкеләр... , кашыклар... сөрттеңме?

**3. Правильно определи время завтрака, обеда и ужина.**

| | | |
|---|---|---|
| Иртәнге аш | ? | көндезге сәгать 12 дә була. |
| Көндезге аш | | кичке сәгать 6 да була. |
| Кичке аш | | иртәнге сәгать 7 дә була. |

**4. Как ты скажешь, если:**
— ты завтракаешь дома;
— обедаешь в школе;
— ты поел в столовой?

**5. Поинтересуйся у друга:**
— есть ли у них в школе столовая;
— вкусно ли готовят;
— кушает ли он в столовой.

**6. Попроси маму:**
— испечь чакчак;
— сварить гречневую кашу;
— сделать чай с молоком.

**7. Как попросишь в столовой:**
— ложку, вилку, нож;
— суп, чай, молоко?

**8. Предложи другу:**
— сесть за стол;
— попить чай;
— поесть вкусный, горячий суп.

**9. Дополни диалог.**
— Оля, син нәрсә ашыйсың?
— ... .
— ... ?
— Юк, миңа ак ипи кирәк түгел, миңа кара ипи кирәк.

**Без әти-әниләргә булышабыз**

**1. Вместо точек вставь нужные буквы.**

Б..зн..ң гаил.. бик тату. Б..з ..йд.. алты к..ш.. : ..ти, ..ни, абый һ..м мин, бабай бел..н ..би.

**2. Выбери правильное окончание.**

1) Рөстәмнең әби... авылда яши.
   а) -се; ә) -е; б) -не.
2) Минем апа... сатучы булып эшли.
   а) -ң; ә) -ны; б) -м.
3) Концертка синең әни... килдеме?
   а) -ң; ә) -ең; б) -ем.

**3. Спроси:**

— есть ли перед школой стадион;
— кто живёт рядом с Димой;
— кто сидит за столом;
— что есть перед домом?

**4. Найди ответ с противоположным значением.**

а) эшчән — тырыш;
ә) баллы — татлы;
б) яхшы — әйбәт;
в) эшчән — ялкау.

**5. Сообщи матери, что:**

— ты не идёшь в магазин;
— Коля не идёт в школу;
— Юля не моет посуду;
— ты не читаешь книгу.

**6. Твой друг пришёл к тебе в гости.**

1) Пригласи друга пить чай.
2) Предложи ему чай с мёдом или с лимоном.
3) Спроси, надо ли ему молока, сахара.

**7. Вместо многоточий вставь нужные реплики.**

— Оля, сезнең гаиләдә кемнәр бар?
— ...
— Әтиең кайда эшли?
— Минем әтием заводта эшли, ә синең әтиең?
— ...

**8. Составь рассказ на тему «Безнең гаилә».**

### Туган көн — күңелле бәйрәм

**1. Подбери к данным словам антонимы.**

кечкенә — ...
тәрбияле — ...
тәмле — ...
яхшы — ...
баллы — ...
акыллы — ... .

**2. Вспомни и напиши, какие вежливые слова говорят:**
а) при встрече; б) перед сном; в) при приглашении гостей к столу?

**3. Спроси у друга:**
— когда у него день рождения;
— сколько ему лет;
— во сколько начинается праздник.

**4. Спроси у друга о том:**
— идёт ли он на день рождения;
— какой подарок он купил;
— во сколько часов идёт он на день рождения.

**5. Поздравь друга с днём рождения.**

**6. Составь диалог, используя данные фразы.**


Мөмкинме? Исәнмесез! Кер, утыр. Рәхмәт. Утыр, чәй эчәбез. Нинди матур табын! Өчпочмак белән эч. Әйдә, тагын эч. Чәй бик тәмле. Өчпочмак та бик тәмле.

## Яраткан уеннарыбыз

**1. Переведи данные слова и словосочетания и запиши их в транскрипции.**

Холодно, снег, мягкий, длинный, короткий, катается на лыжах, сани.

**2. Найди слова с противоположными значениями.**



| | |
|---|---|
| салкын | астында |
| ап-ак | озын |
| өстендә | кап-кара |
| кыска | вак |
| эре | җылы |

**3. Как скажешь о том, что:**
— играешь в хоккей (футбол, баскетбол, волейбол, теннис, бадминтон)?

**4. Позови друга:**

— вместе играть на улице;
— кататься на лыжах;
— кататься на санках;
— играть в хоккей.

**5. Тебе хочется кататься на санках, но у тебя их нет. Как попросишь у друга санки?**

**6. Спроси друга:**

— хорошо ли он катается на лыжах;
— есть ли у него лыжи (коньки).

**7. Представь, что эти действия произошли. Как изменятся глаголы?**

1) Ул хоккей уйный. — ... 2) Мин чаңгыда шуам. — ... 3) Син стадионга барасың. — ...

**8. Дополни диалог.**

— ... ?
— Мин стадионга барам.
— Стадионда нишлисең?
— ... .

**Шәһәрдә һәм авылда**

**1. Переведи названия городов и составь с ними предложения.**

Казань, Чистополь, Заинск, Набережные Челны, Елабуга, Нижнекамск.

**2. Вместо точек вставь нужные окончания.**

Мин Казан... барам.
Мин Казан... кайтам.
Мин Казан... яшим.

**3. Переведи и составь предложения с данными словами.**

Около, под, над, за.

**4. Скажи о том, что:**
— в Казани много музеев;
— Коля живёт в Чистополе;
— Казань — большой красивый город;
— ты живёшь в девятиэтажном доме;
— в вашей квартире есть кухня, зал, спальня.

**5. Дополни диалог.**
— ... ?
— Мин бишенче мәктәптә укыйм.
— Мәктәпкә ничек барасың?
— ... .
— … ?
— Мәктәп янында тукталыш, зур стадион бар.
— Мәктәпкә сәгать ничәдә барасың?
— ... .

**6. Позови друга пойти с тобой:**
— в цирк, в аквапарк, в лес.

**7. Сообщи о том, что:**
— Петр Иванович — учитель;
— тётя Клава — продавщица;
— мама Карима — швея;
— сестра Азата — библиотекарь.

**8. Как скажешь о том, что:**
— в Казань едешь на автобусе;
— на улице Баумана много красивых зданий;
— в Казани живут твои друзья?

**9. Спроси у друга:**
— сколько ему лет;
— в каком доме он живёт;
— в какой квартире он живёт;
— в какой школе он учится.

**10. Напиши рассказ о своей деревне (о своём городе).**

## Милли бәйрәмнәр

**1. Переведи на татарский язык.**

Русские, татары, чуваши, марийцы, мордва, башкиры.

**2. Как скажешь о том, что:**

— в Татарстане живёт много национальностей;
— они живут дружно;
— Сабантуй, Масленица, Навруз, Рождество — наши любимые праздник?

**3. Продолжи названия татарской национальной одежды.**

Калфак, … , … , … , … , … .

**4. Спроси у друга:**

— с кем он идет на праздник;
— во сколько начинается праздник;
— что он делает на празднике.

**5. Позови друга в гости. Скажи, что твоя бабушка (мама) испекла вкусные блины.**

**6. Дополни диалог.**

— ... ?
— Мин бәйрәмгә барам.
— ... ?
— Дуслар белән барам.

## Кечкенә дусларыбыз

**1. Дополни диалог.**

— ... ?
— Әйе, минем этем бар.
— Аның исеме ничек?
— ... .
— Ул нинди?
— ... .
— Ул нәрсә ярата?
— ... .

**2. Скажи о том, что:**

— у Айрата есть большая, красивая собака;
— Айрат каждый день гуляет с собакой;
— а у Айнура собака маленькая;
— у тебя есть красивая кошка.

**3. Дополни диалог.**

— ... ?
— Аның исеме Акбай.
— Ул нинди командалар белә?
— ... .
— ... ?
— Әйе, минем песием дә бар.
— Ул нинди?
— ... .

## Уеннар

**1. «На воздушном шаре» уены.**

— Ребята, мы на воздушном лайнере отправляемся в путешествие. По правилам игры нужно делать посадку только в городах Татарстана.

Балалар самолетта очкан хәрәкәтләр ясыйлар, укытучы төрле шәһәр исемнәрен атый. Укытучы Татарстан шәһәрен атаганда, укучылар чүгәлиләр һәм шәһәр исемнәрен хор белән кабатлыйлар. Шул ук вакытта Россия һәм чит илдәге шәһәр исемнәрен аера һәм әйтә белү күнекмәләре камилләштерелә.

**2. «Угадай» уены.**

Бер бала шәһәр исемен уйлый. Калганнары нинди шәһәр икәнен белергә тиеш.

— Бу Казанмы?

— Бу Казан түгел, бу — Зәй.

**3. «Белмәмеш» уены.** Укытучы сан язылган карточкаларны күрсәтә һәм Белмәмеш исеменнән аны ялгыш итеп әйтә. Мәсәлән, 7 саны язылган карточканы күрсәтә һәм 6 дип әйтә. Балалар төзәтәләр: «Юк, бу 6 түгел, бу — 7».

**4. «Угадай число» уены.** Укытучы сан әйтә, ә балалар бу санга кадәр булган һәм аннан соң килүче санны әйтәләр.

**5. Уен.** Укытучы микъдар санын күрсәтә, укучылар тәртип санын әйтергә тиеш.

**6. Уен.** Укучылар бер рәткә тезелеп басалар, һәм физкультура дәресендәге кебек, һәрберсе үзенең урынын тәртип саны белән атый. Беренче, икенче һ.б.

**7. «Тылсымлы тартма» уены.**

Балалар тартмадан уенчыклар яисә рәсемнәр алалар. Ничәнче уенчыкны алуларына карап, аның исемен һәм тәртип санын әйтәләр.

— Беренче — куян, икенче — аю һ.б.

**8. «Нәрсә артык?» уены.**

Фланелеграфка уку-язу әсбапларының һәм гөмбә (чәчәк) рәсемнәре беркетелә.

— Ребята, что здесь лишнее? Почему?

(Уен барышында уку-язу әсбапларының исемнәре кабатлана.)

**9. «Сумкада нәрсә бар?» уены.** Укытучы балалар янына килә, аларга сораулар бирә:

— Сумкада каләм бармы?

— Әйе, сумкада каләм бар.
— Сумкада аю бармы?
— Сумкада аю юк.

**10. Шул ук уен укучы-укучы арасында уйналырга мөмкин.**

**11. «Матур сөйләшәбез» уены.**

Укучылар предметларның исемнәрен йтәләр һәм аларны үзләренә сорап алалар.

— Бу — китап.
— Миңа китап бир әле.

**12. «Строка внимательных» уены.** Сейчас вам придется быть очень, очень внимательными. Если я подниму левую руку вверх, вы называете диких животных, а если подниму вверх правую руку — назовёте домашних животных.

**13. Уен.** Укытучы предмет рәсемнәрен күрсәтә, балалар сорау куя.

Куян рәсеме — нәрсә? Кыз рәсеме — кем?

**14. Уен.** Уенчыклар (кыргый хайваннар һәм йорт хайваннары) яисә аларның рәсемнәре буталып бирелә. Укучылар чиратлашып рәсемне (уенчыкларны) алалар, хайваннарның исемнәрен атыйлар һәм кайда яшәвен әйтәләр.

— Бу төлке. Ул урманда яши.
— Бу сыер. Ул авылда яши.

**15. Уен.**

— Ребята, представьте себе, что вы артисты кукольного театра. Озвучьте животных. Как скажет каждое животное, кто он и где живёт.

— Мин аю. Мин урманда яшим.
— Мин үрдәк. Мин авылда яшим.
— Мин фил. Мин зоопаркта яшим.

**16. Уен.** Фланелеграфка хайваннар, кошлар рәсеме куела. Диалоглар:

а) — Монда ат бармы?
— Әйе, монда ат бар.

ә) — Бу атмы?
— Юк, бу ат түгел.

**17. Физкультминутка** өчен «Чебиләр зарядкасы» җырының 1 нче куплеты һәм кушымтасын алырга мөмкин.

Нәни чебиләр барсы да
Сары майка кияләр.
Зарядка ясарга диеп
Бер урынга киләләр.

Корт-корт, корт-корт,
Сары майка кияләр.
Корт-корт, корт-корт,
Бер урынга киләләр.

**18. «Бу кемгә?» уены.** Укытучы уку-язу әсбаплары рәсемнәрен өстәлгә таратып куя. Укучы рәсемне ала һәм сорый: «Бу кемгә?» Балалар җавап бирәләр: «Нинага». (Нина уенчык ала һәм әйтә: бу уенчык миңа.)

**19. Уен.** Уен өчен уенчыклар һәм рәсемнәр әзерләнә.

— Ребята, у нас сегодня конкурс-отбор артистов для озвучивания роли животных из разных сказок. Каждый из вас по очереди выходит и выбирает рисунок (игрушку) с изображением животного или птицы. Лиса из сказки «Болтливая утка» возвращается из деревни, как она об этом скажет.

— *Мин авылдан кайтам.*

Медвежонок возвращается из лесной школы.

— *Мин мәктәптән кайтам.*

Заяц из мультфильма «Ну, погоди» участвовал в кроссе и возвращается.

— *Мин кросстан кайтам.*

Кот Матроскин из мультфильма «Простоквашино» возвращается из города. Как он об этом скажет?

— *Мин шәһәрдән кайтам.*

Волк возвращается из стадиона. Как он скажет?

— *Мин стадионнан кайтам.*

**20. Уен.** Укытучы өстәлендә уенчыклар яисә рәсемнәр. Балалар чиратлашып өстәлдән уенчыкны алалар. Уенчыкны алганда: «Бу — минем куяным. Бу — минем этем», — дип әйтәләр.

**21. Рифмовка** өйрәнү.

Акбай бик тиз йөгерә,
Менә шулай сикерә.
Кил, Акбай, кил яныма,
Сыйпыйм сине тагын да.

Балалар рифмовканы хәрәкәтләр белән күрсәтеп сөйлиләр. Аны физкультминут итеп тә кулланырга мөмкин.

**22. Уен.**

— Ребята, вспомните, в каких сказках встречаются овощи. Овощ назовите по-татарски, а название сказки — по-русски. Например, кабак — «Золушка»; помидор, суган — «Чипполино», шалкан — «Репка».

**23. «Нәрсә юк?» уены.** Укытучы балаларга яшелчә рәсемнәре күрсәтә. Аннан соң берсен сиздермичә генә яшерә. Балалар нәрсә юк икәнен әйтергә тиеш.

**24. «Баскыч» уены.**

Бу уен аша яшелчә исемнәре истә калдырыла. Бер бала чыгып, яшелчә

исемен әйтә. Мәсәлән, кишер. Икенче бала, аның янына басып, ул әйткән сүзне кабатлый һәм үзе уйлаган яшелчә исемен әйтә. Ул беренче баланың алдына баса. Өченче бала бу ике баланың һәрберсе янына басып, аларның сүзләрен әйтә һәм икенче баланың алдына басып, үзе уйлаган сүзне әйтә. Балалар шулай баскыч төзиләр, яшелчә исемнәрен әйтәләр. Бу уен балаларның игътибарын, хәтер күләмен үстерү өчен дә бик файдалы.

**25. Балалар арасында уен формасында диалогик сөйләм оештырыла.** Укытучы һәрбер балага яшелчә рәсемнәре тарата. Укучылар арасында түбәндәге диалог оештырыла:

— *Оля, миңа кыяр бир әле. Мин кыяр яратам.*

— *Мә.*

— *Рәхмәт.*

**26. Рифмовка — «Без чәчәбез яшелчә».**

Без чәчәбез яшелчә:
Кишер, кыяр, кәбестә.
Су сибәбез, су сибәбез.
Алар үсә дә үсә.

Күктә кояш елмая,
Җылы яңгырлар ява,
Рәхәт кенә җил исә,
Яшелчәләр зур үсә.

Рифмовка хәрәкәтләр белән күрсәтеп сөйләнелә. Аны физкультминут итеп файдаланырга була.

**27. «Не соглашайся» уены.**

— Один из вас придумывает предложение о том , что он любит, а другой говорит, что он этого не любит.

— *Мин суган яратам.*

— *Ә мин суган яратмыйм.*

**28. «Ул нинди?» уены** аша диалогик сөйләм үстерү. Өстәлдә яшелчә, җиләк-җимеш рәсемнәре.

— Ребята, по условиям игры, выбрав овощ или фрукт, вы говорите, что любите его и какой он. Потом сами спрашиваете, у кого хотите, что он любит.

Бала үзе теләгән яшелчә яисә җиләк-җимешне сайлап ала һәм әйтә :

— *Мин помидор яратам. Ул кызыл, тәмле.*

— *Алия, ә син нәрсә яратасың?*

**29. «Нәрсә артык» уены.**

Укытучы өстәлендә предмет рәсемнәреннән логик рәт тезелә. Мәсәлән, яшелчә рәсемнәре арасында 1 җиләк-җимеш рәсеме. Укучы логик рәттә нинди предмет артык икәнен табарга һәм аның исемен әйтергә тиеш.

Шул ук уенны бер төрле төстәге предмет рәсемнәрен кулланып уйнарга мөмкин.

**30. «Төрлечә әйт» уены.** Сүзләр, сүзтезмәләр балаларның хәтерендә калсын өчен, уен формасында болай эшләргә була:

а) Ребята, повторите эти слова за мной.

ә) А теперь эти слова произнесём с удивлением.

б) А сейчас — с восхищением.

в) А теперь — шёпотом.

г) Повернулись к друг другу и сообщаем об этих явлениях природы.

д) А теперь повернулись ко мне, я буду говорить по-русски, а вы скажете по-татарски.

**31. «Көн нинди? « уены.** Укытучы сүзләрне әйткәндә, балалар хәрәкәтләр белән күрсәтәләр.

Башта укытучы сүзләрне үзе әйтә, соңыннан укытучы урынына уенны балалар да уздырырга мөмкин. Мәсәлән, салкын — салкыннан калтыранган кыяфәт чыгаралар; кар ява — балалар кар бөртекләре төшкән кебек, әкрен генә чүгәләр; җил исә — куллары белән сулга, уңга хәрәкәт ясыйлар.

**32. Уен.** Укытучы өстәлендә Кыш бабай капчыгы. Анда төрле уенчыклар яисә уенчык рәсемнәре.

— Ребята, я сегодня исполняю роль Деда Мороза. Кто по-татарски спросит, есть ли ему подарок. А когда Дед Мороз покажет подарок, назовёт его по-татарски, тот получит этот подарок.

— Кыш бабай, миңа бүләк бармы?

— Бар (укытучы капчыктан алып күрсәтә).

— Бу куян (укучы атый).

— Мә сиңа куян.

(Укучылар өйрәнә төшкәч, Кыш бабай ролен балалар үзләре үти ала.)

**33. «Уйла һәм әйт» уены.** Укытучы өс киемнәрен әйтә (рәсем күрсәтә). Укучы, үрнәк буенча, тән әгъзасы исемен әйтергә тиеш. Әйтик, бияләй — кул; күзлек — күз; бүрек — баш һ.б.

**34. Физкультминут.**

Укытучы артыннан балалар хәрәкәтләр белән күрсәтәләр.

Песи йоклый.

Песи уяна.

Песи уңга карый, сулга карый.

Песи ашый, песи сөт эчә.

Песи юына.

Песи үсә.

**35. «Мин нәрсә бирәм?» уены.**

Укучыларның өстәлләрендә таратма материаллар (уенчык яисә җиләк-җимеш, яшелчә рәсемнәре). Балалар шуларны файдаланып, җөмләләр төзиләр. Мәсәлән,

— *Мин Сашага машина бирәм.*

— *Мин Розага курчак бирәм.*

**36. «Угадай» уены.**

Балаларның өстәлләрендә татар халык ашлары рәсемнәре. Укытучы нинди дә булса ризыкны атый, ә укучылар аның рәсемен күрсәтәләр. Укытучы урынына балалар үзләре уенны алып барырга да мөмкин.

**37. «Кунакка килү» уены.**

— Ребята, как вы думаете, какие сказочные герои ходят в гости к друг другу. Выбирайте себе персонажей и будете их озвучивать.

Балалар укытучы өстәлендәге таратма материалдан Чипполино, Винни-Пух, Буратино, Шүрәле, Күбәләк, Сертотмас үрдәк һ.б. рәсемнәрне алалар һәм кунак каршы алу диалогын сөйләшәләр.

**38. Уен. «Карамыйча әйт».**

Теләк буенча бер укучы такта алдына чыга. Аңа битлек кидерелә. Укучы битлекне күрмәскә тиеш. Үзенә нинди битлек кидерелүен ул класска сораулар бирү аша белә ала. Калган укучылар «әйе», «юк» дип җавап бирәләр. Ул белгәч, башка укучы чыга.

Бу очракта кошлар битлекләре белән уйнау өчен сораулар тәкъдим ителә.

— *Ул йөриме?*

— *Ул очамы?*

— *Ул йөгерәме?*

— *Ул сикерәме?*

— *Ул йөзәме?*

— *Зурмы?*

— *Кечкенәме?*

— *Ул карамы?*

— *Акмы?*

— *Сорымы?*

— *Урманда яшиме?*

— *Авылда яшиме?*

— *Кишер яратамы? Һ.б.(Балаларның әзерлегенә карап, сораулар төрлечә бирелә).*

# ЭЧТӘЛЕК

«Татар теле» укыту-методик комплекты белән эшләү үзенчәлекләре ........ 3

Ишетеп аңлау күнегүләре ........................................................................ 4

Федераль эш программасына нигезләнгән календарь-тематик план ........ 25

3 нче сыйныф рус балаларының татар теле буенча белем
дәрәҗәләрен билгеләү биремнәре ............................................................ 32

Уеннар....................................................................................................... 42

*Методическое пособие*

**Хайдарова** Роза Закиевна
**Ахметзянова** Гульназ Магсумзяновна
**Гиниятуллина** Лейсан Адиповна

Книга для учителей к учебнику «Татар теле. 3 класс»

3 класс

Редактор:
**Ильгизар Закиев**

Компьютерная вёрстка
**Елены Шараповой**

Подписано в печать 20.08.2024.
Формат 170x205 1/4. Бумага офсетная.
Гарнитура «Arial». Тираж экз. Заказ №

Издательство «Татармультфильм»
420066, г. Казань, пер. Односторонки Гривки, д. 32, помещ. 2

Отпечатано в полном соответствии с качеством
предоставленных материалов в типографии



9 785906 508492

«Татармультфильм»